**Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләрендәге**
**8 нче сыйныф укучылары өчен татар теле һәм әдәбиятыннан**
**IV Халыкара олимпиада биремнәре**

1. Ш.Камалның “Акчарлаклар” повестенда яки “Буранда” хикәясендә образларны төркемнәргә бүлеп языгыз:

Төп герой;

Ярдәмче герой;

Эпизодик герой;

Әйбер образлары;

Ясалма образлар.

Әсәрдә табигать образлары нинди функция башкара? Җавабыгызны, әсәр сюжетына нигезләнеп, 7-8 җөмлә белән төгәл итеп языгыз (20 балл).

2. Ш.Камал иҗат иткән “Акчарлаклар” әсәренең повесть жанрына яки “Буранда” әсәренең хикәя жанрына каравын дәлилләгез, үз фикерегезне әсәр мисалында раслап барыгыз (20 балл).

3. *Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын; / Мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын* (Г.Тукай). Әлеге шигырь юлларына таянып, 100 сүздән дә ким булмаган күләмдә инша языгыз (20 балл)

4. Түбәндә тәкъдим ителгән аңлатмаларга нигезләнеп һәм җавап өлешендә күрсәтелгән сүзне истә тотып, туры килә торган фразеологик әйтелмәләрне языгыз. (Һәр дөрес җавап - 2 балл; барлыгы 10 балл).

*А) кешене алдау, ялганга ышандыру*

________________*атка*______________________________________

*Ә) бик вак, бик озак, авырлык, түземлек белән эшләнә торган эш*

_________________*кое*_______________________________________

*Б) бара торган эш тукталу, эш тоткарлыкка очрау*

__________*комга*____________________________________________

*В) бик караңгы*

________*төртсәң*_________________________________________

*Г) бер кеше турында сөйләп торганда үзе килеп керсә әйтелә торган гыйбарә*

_____________*озын*____________________________________

5. Түбәндә бирелгән сүз парларына өчәр хәреф өстәп, сүзләр языгыз. Беренче сүзнең ахырына куелган хәрефләр икенче сүзнең башында булырга тиеш. **(**Һәр дөрес җавап - 1 балл; барлыгы 5 балл).

   АВР . . . - . . . ТОР

   СИК . . . - . . . ӘК

   ТУЛ . . . - . . . ТА

   ФОН . . . – . . . КЕР

   АЧ . . . - . . . КЫРУ

6. . *Яхшылыкка эреп китәм, <u>балавыз</u> мин, / Мактап сөйлим изге эшне* – бал авыз *мин* (Г.Тукай) шигъри юлларында аерып күрсәтелгән сүзләрнең мәгънәләрен аңлатыгыз. Мондый сүзләрне ничек атап йөртәләр? Әлеге тел күренеше турында белгәннәрегезне языгыз. (Барлыгы 10 балл).

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

7. Өзекне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез (Һәр бирем - 3 балл; барлыгы 15 балл).

*1) Синнән ераклашкан саен якыная гына барабыз <...> ахры <...> туган җир! 2) Һәр түмгәгең, һәр борылышың, һәр сукмагың күз алдында. 3) Әйтерсең лә, синнән чыгып киткәндә ике арадагы ниндидер бер тамыр урталай өзелгән дә шуның очлары кабат ялгану өчен, еллар үткән саен, бер-берсенә ныграк тартылалар. 4) Бу тойгы авылдан бик еракта, читтә яшәүчеләргә генә таныш. 5) Татарча җыр гына ишет – сагыш сөреме күзләрне, борыннарны, тамак төпләрен әчеттерә башлый. 6) Гүя синең йөрәгең түрендә сизелер-сизелмәс кенә булып һәрвакыт моң чишмәсе тибә. 7) Фәрит кайчан гына кайтса да, авылны күрүгә үк, ул чишмәнең ургый башлавын тоя, аның кайнарлыгы бөтен тәненә тарала, һәр күзәнәгеен били, тел сүз әйтергә әйләнми, елап та, елмаеп та булмый... (Ф. Садриев)*

1. 1 нче җөмләдә <...> тамгалары урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз.

____________________________________________________________

2. Өзектән кушма рәвешне язып алыгыз.

____________________________________________________________

3. 2-3 нче җөмләләрдән ирен гармониясе күзәтелгән сүзләрне язып алыгыз.

______________________________________________________________

4. 4 нче җөмләнең төрен билгеләгез.

______________________________________________________________

5. Капма-каршы мәгънәдәге сүзләр кулланылган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә языгыз.

______________________________________________________________